ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1704**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 4 октябрендәге 2417 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 3 декабрендәге 3088 номерлы, 2021 елның 29 декабрендәге 3427 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 959 номерлы, 2022 елның 10 августындагы 2082 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга, грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 22 декабрендәге 2385 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 4 октябрендәге 2417 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 3 декабрендәге 3088 номерлы, 2021 елның 29 декабрендәге 3427 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 959 номерлы, 2022 елның 10 августындагы 2082 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 2.2 пунктының алтынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «- сайлап алуда катнашучылар , шул исәптән Россия Федерациясе Финанс

министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән (алга таба - офшор компанияләре) теркәлү урыны дәүләт яисә территория булган чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтелгән (өченче зат аша) катнашуы 25 процenttан артып киткән Россия юридик затлар (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) булырга тиеш түгел. затлары булырга тиеш түгел. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин